КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 июль г.Казань № 675

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 8 июль, 655 нче карарына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне кертү турында» 2022 ел, 8 июль, 655 нче карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасының Аксубай, Әлки, Апас, Югары Ослан, Биектау, Кайбыч, Питрәч, Лаеш, Арча, Әтнә, Балтач, Саба, Теләче, Нурлат, Алабуга, Мамадыш, Тукай, Менделеевск, Минзәлә, Актаныш, Зеленодольск, Чүпрәле, Әгерҗе, Чистай, Алексеевск, Яңа Чишмә, Түбән Кама, Зәй, Сарман, Мөслим, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә, Ютазы, Баулы муниципаль районнары һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендәге урман фонды территориясендә урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында гражданнарның урманнарда булуын, аларга транспорт чаралары белән керүен чикләүне һәм урманнарда эшләрнең билгеле бер төрләрен башкаруны бу карар үз көченә кергән көннән 21 календарь көнгә (Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә урманнардан файдалану буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларның гомуми файдаланудагы юллар буйлап үтәли йөрүдән тыш) кертергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин